РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июня 2020 г. г. Альметьевск № 383

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 17 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмә хакында»гы 432 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 17 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмә хакында»гы 432 нче номерлы карарына (2015 елның 10 декабрендәге 38 нче номерлы Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Җәмәгать Советы структурасы һәм эшчәнлеген оештыру» 4 бүлектә егерме беренче абзацны төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарәгә кагылышлы сораулар буенча даими комиссиясенә (Багманов И.Р.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

Заказ № 1146-100